ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 февраль 2025ел № 875

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3682 номерлы Карары белән расланган җир участогы бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елны 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3682 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 9 июнендәге 2968 номерлы, 2023 елның 16 июнендәге 5186 номерлы, 2024 елның 5 сентябрендәге 5725 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган җир участогы бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.3.2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 пунктчада «территорияне комплекслы үстерү» сүзләреннән соң «яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта» сүзләрен өстәргә;

2) 9 пунктчада «территорияне, яки» сүзләрен «территорияне яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, яки» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 пунктчада «территорияне, һәм» сүзләрен «территорияне яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан,

күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, һәм» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов